**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Түбән Биш авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**22.09.2020 ел** **№ 6**

**Муниципаль хезмәт вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш, Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге башкарма комитеты баш хисапчысы хезмәтенә түләүне оештыру турында нигезләмә хакында" 2019 елның 27 маендагы 168 номерлы Зәй муниципаль районының Түбән Биш авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясенең 1998 елның 31 июлендәге 145-ФЗ номерлы Бюджет кодексы, «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында» 2020 елның 5 августындагы 655 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. "Муниципаль хезмәт вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш, Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге башкарма комитеты баш хисапчысы хезмәтенә түләүне оештыру турында нигезләмә хакында" 2019 елның 29 маендагы 178 номерлы Зәй муниципаль районының Түбән Биш авыл җирлеге Советы карары белән расланган муниципаль хезмәт вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш, Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге башкарма комитеты баш хисапчысы хезмәтенә түләүне оештыру турында нигезләмәнең 2.2 пунктына үзгәреш кертергә һәм "баш хисапчы" юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| Баш хисапчы | 16 171 сум | 17 510 сум |
| Хисапчы | - | 14 935 сум |

2. Штат расписаниеләренә  һәм локаль актларга тиешле үзгәрешләрне кертергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районыныңБигешавыл җирлеге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Карар 2020 елның 1 октябреннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **Д.В.Насертдинов**